РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«29» май 2026 г. г. Альметьевск № 54

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2013 елның 15 ноябрендәге 343 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының муниципаль юл фондын төзү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2026 елның 18 маендагы 02-08-01 номерлы протестын карап,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2013 елның 15 ноябрендәге 343 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының муниципаль юл фондын төзү турында»гы карарына (Әлмәт муниципаль районы Советының 2015 елның 10 декабрендәге 26 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга кушымтада:

а) тәртипнең 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Муниципаль юл фонды (алга таба – юл фонды) - Әлмәт муниципаль районы бюджетының (алга таба – җирле бюджет) гомуми файдаланудагы җирле (муниципаль) әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү, шулай ук район торак пунктларындагы күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренә керү юлларын капиталь ремонтлау һәм ремонтлау максатларында кулланылырга тиешле.»;

б) тәртипнең 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына җирле бюджет турында Әлмәт муниципаль районы Советы карары белән район бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләменнән ким булмаган күләмдә раслана:

1) Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган автомобиль бензинына, турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, дизель һәм (яисә) карбюраторлы (инжекторлы) двигательләр өчен мотор майларына чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән расланган дифференциацияләнгән бүлү нормативлары нигезендә җирле бюджетка күчерелергә тиешле акцизлар;

2) транспорт салымыннан җирле бюджетлар керемнәре (әгәр Татарстан Республикасы законы белән транспорт салымыннан җирле бюджетларга чигерүләрнең бердәм нормативлары билгеләнгән булса);

3) җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына авыр йөкле транспорт чаралары белән китерелә торган зыянны каплау исәбенә түләүдән җирле бюджетлар керемнәре;

4) авыр йөк һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен штрафлардан җирле бюджетлар керемнәре;

5) гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә физик һәм юридик затлардан кире кайтарылмый торган кертемнәрдән, шул исәптән ирекле иганәләрдән җирле бюджет керемнәре.»;

в) тәртипнең 3.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Юл фондының бюджет ассигнованиеләре:

1) районның шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан юлларны төзү (реконструкцияләү), капиталь ремонтлау һәм ремонтлау;

2) районның шәһәр һәм авыл җирлекләрендәге күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренә керү юлларын капиталь ремонтлау һәм ремонтлау.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, салымнар һәм җыемнар буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Рәхимов И.М.).

Муниципаль район Башлыгы Г.М. Хәбутдинова

«СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА»